

Һәр ел сәләтле балалар очен Мордовиянен Краснослабодск районындагы «Сивинь» жәйге ял лагере базасында «Яшә, туган тел!» этномәдәни регионара сменасы эшли. Оештыручысы – Мордовия республикасы мәгариф министрлыгы. Быел ул 10 июльдә тантаналы рәвештә 13 тапкыр ачылды. 27нче июльгә кадәр 80 сәләтле бала ял итәр. Рус, мордва һәм татар халыкнын телен ойрәнv теләге булдыру, тарихына кызыксыну уяту, халыкларнын милли-мәдәни vзен-чәлекләрен саклау, дуслыкны ныгыту, сәламәт яшәv нигезләрен формалаштыру – балалар очен оештырылган «Яшә, туган тел!» дигән этник лагерьнен максаты.      Бу лагерьдә Мордовиядән, Татарстаннан (Бугульма, Альметьевск шәһәрләреннән дә), Оренбург, Тvбәншәһәр, Ульян, Мәскәv (Владимирдан) олкәләреннән һәм Мәскәvдән туган теле, әдәбияты олимпиадаларында жинvчеләр, туган теле һәм мәдәнияты буенча торле конкурсларда, фольклор торкемнәрендә катнашкан балалар ял итә башладылар. Икенче ел беррәттән татар группасы белән Ләмберә районы Черемиш гомуми топ мәктәбенен татар теле һәм әдәбияты укытучысы Фазия Фәрит кызы Боярова эшли. Быел татар милләтле балаларыбыздан Ләмберә районы Пензятка авылыннан Карабдаева Сабина, Салимова Алина һәм Черемиштән – Зинченко Диана, Мансуров Ильдар, Маринова Дарина, Сюбаев Адель, Чураков Динар бу ял лагерена килделәр.

- Черемишлеләр тантаналы лагерь ачылышы вакытында «Яратыгыз» жырын башкардылар, - ди Фазия Фәрит кызы Боярова. Тамак ялгап, ял итеп алгач, зур концерт vтте. Анда да сәләтләрен кvрсәтеп олгерделәр; Мансуров Ильдар «Эх, матур кызлар» жырын, Чураков Динар «Әпипә»не башкарып барыбызнын да кvнелләрен кvтәрделәр. Шулай итеп, «Сивинь»дә, сәләтле балалар очен оештырылган этномәдәни лагерьдә, ял итvчеләр туган якларын, анын тарихын тирәнтен vзләштереп, ойләренә сәламәтлекләрен ныгытып, мәдәни баеп (вокал һәм хореография буенча), сабын кайнату серләренә тошенеп, балчыктан һәм агачтан чукып торле фигуралар ясарга ойрәнеп кайтачаклар.